ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.07.2016**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 1809**

Зеленодольск шәһәре, Союзная урамы, 3 нче йорт адресында урнашкан җир кишәрлеген һәм андагы күчемсез милек корылмаларын алу турында

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 26.09.2013 ел, №2178 карары белән расланган, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче Фонд турында» 21.07.2007 ел, №185-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Торак, Җир кодекслары нигезендә муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатларында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Зеленодольск шәһәре, Союзная урамы 3 нче номерлы күпфатирлы торак йорт, шулай ук кушымта булып бирелә торган исемлек нигезендә күрсәтелгән йортның җир кишәрлегендә урнашкан күчемсез милек корылмаларын (торак һәм торак булмаган биналар) муниципаль ихтыяҗлар өчен алырга.
(кушымта).

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштырырга.

3.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:
- алына торган күчемсез милек хокукына ия булучыларга;
- күчемсез милеккә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга;
- МКУ «Торак сәясәте департаменты» на җибәрергә.

4.МУ «Зеленодольск муниципаль районының Мөлкәт һәм Җир мөнәсәбәтләре палатасы» әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслауны тәэмин итәргә тиеш.

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче вакәләтләрен башкаручы А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
Кушымта
13 июль 2016 ел, №1809

Авария хәлендә табылган һәм сүтелергә тиешле, Зеленодольск шәһәре, Союзная урамы, 3 нче йорт адресындагы күпфатирлы торак йортта урнашкан алынырга тиешле күчемсез милек корылмалары
(торак һәм торак булмаган бүлмәләр)
ИСЕМЛЕГЕ

| № кв. |
|---|
| 11 |